| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**13.02.2017** **г. Казань** **№ 285-р**

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның берсүзсез үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының 2017 елның
«13» февралендәге 285-р
номерлы карары белән расланды

# Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар – дәүләт яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен торгларсыз гына алырга хокукы булган физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очраклар искәрмә булып тора.

Дәүләт хезмәтен алырга гариза бирүчеләр булып хезмәтне алучылар яисә тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә дәүләт хезмәте алучы исеменнән эш йөртүче затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) санала.

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән «Калинин» тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-39, 221-40-89.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. П Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Кадастр эшчәнлеге турында” 24.07.2007, № 221-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2007, № 31, 4017 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, №31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 б кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012, №601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

«Гариза бирүченең торглар уздырмыйча җир кишәрлеге алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 12.01. 2015, № 1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 1) (“Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы” (www.pravo.gov.ru) 2015, 28 февраль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында” 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 7) (“Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы” (www.pravo.gov.ru) 27.02.2015);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1, 4 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җиргә аренда түләве турында» 09.02.1995 №74 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Известия Татарстана, 1995, № 28, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, №

880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында" 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 19.10.2011, № 39, 1928 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен, яисә торглар уздырмыйча сатыла ала торган дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 11.06.2015 № 432 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 47-48, ст. 1619, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хөкүмәте – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсе (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 03.10.2007, № 37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомоствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибе турында" 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара арадашлык тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) шул документка нигез булган белешмәләргә туры килмәвенә китерүче Министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Мөрәҗәгатьнең киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләп эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү | РФ ЖК;<br>№ 137-ФЗ Федераль закон;<br>ТР ЖК 4,18 ст.;<br>Нигезләмә п. 3.3.19 |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсе.<br>Җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе.<br>Җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирүдән баш тарту | РФ ЖК 39.3, 39.6, 39.20 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәт мөрәҗәгать кабул ителгәннән соң утыз көн эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган | ЖК РФ 39.17 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны күрсәтү тәртибе | 1. Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрне сатканда түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1.1. Җир кишәрлеген ясарга кирәк булганда яисә №218-ФЗ Федераль закон нигезендә җир кишәрлегенең чикләрен анықларга кирәк булган очракта, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать.<br>1.2. Җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать (РФ ЖК 39.5 ст.ның 4 һәм 5 подпунктларында каралган очракларда җир кишәрлеген милек итеп бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукы беткән көнгә кадәр, әлеге хокукның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш.<br>РФ ЖК 39.3 ст.ның 2 пунктындагы 7 подпунктында, 39.6 ст.ның 2 пунктындагы 11 подпунктында каралган очракларда җир кишәрлеген милек итеп бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) куллануның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш.<br>Җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр беркетелә:<br>1.2.1. РФ ЖК 39.15 ст.ның 2 пунктындагы 1 һәм 4 – 6 пунктыларында каралган документлар. Әлеге документлар вәкаләтле органга җир кишәрлеген | РФ ЖК 39.3, 39.6, 39.15 ст.;<br>Боерык № 1;<br>№ 218-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать белән юлланган булса, әлеге мөрәҗәгатьне карап җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән булса, күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми;<br>1.2.2. гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ, юридик яисә физик затның вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта – Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик яисә физик затның вәкаләтләрен раслаучы документ, аның күчермәсе мөрәҗәгатьне кабул итүче белгеч тарафыннан раслана һәм тапшырылган мөрәҗәгатькә беркетелә;<br>Гариза бирүче тапшыра торган документлар исемлеге, хезмәтне алучының категориясенә карап, 9нчы кушымтада китерелгән.<br>2. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен арендага биргәндә түбәндәгеләр тапшырыла<br>2.1. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать – № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә, җир кишәрлегенең чикләре тәгаенләнергә тиеш булганда яисә җир кишәрлеген ясарга кирәк булганда яисә<br>2.2. җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать (РФ ҖК 39.3 ст.ның 2 пунктындагы 7 подпунктында, 39.6 | |

| | | |
|---|---|---|
| | ст.ның 2 пунктындагы 11 подпунктында каралган очракларда җир кишәрлеген арендага бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) куллануның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш).<br>Җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатькә түбәндәгеләр беркетелә:<br>2.2.1. РФ ҖК 39.15 ст.ның 2 пунктындагы 1 һәм 4 – 6 пунктыларында каралган документлар. Әлеге документлар вәкаләтле органга җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать белән юлланган булса, әлеге мөрәҗәгатьне карап җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән булса, күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми;<br>2.2.2. гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ, юридик яисә физик затның вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта – Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик яисә физик затның вәкаләтләрен раслаучы документ, аның күчермәсе мөрәҗәгатьне кабул итүче белгеч тарафыннан раслана һәм тапшырылган мөрәҗәгатькә беркетелә;<br>Гариза бирүче тапшыра торган документлар исемлеге, хезмәтне алучының категориясенә карап, 10нчы кушымтада китерелгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда саклanган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклanган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алына торган документлар исемлеге, хезмәтне алучыларның категориясенә карап, 9нчы, 10нчы кушымталарда китерелгән.<br>Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>- юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә алу өчен - Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә;<br>- гариза бирүче турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмә алу өчен - Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә;<br>- җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан белешмә алу өчен - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең идарәсеннән. | РФ ЖК 39.17 ст;<br>Боерык № 1;<br>ТР МК № 675 карары |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1.Мөрәҗәгать РФ ЖК 39.17 ст.ның 1 пункты нигезләмәләренә туры килми, башка вәкаләтле органга тапшырылган яисш мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелмәгән.<br>2. Мөрәҗәгатьтә һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән урыннар булуы.<br>3. Министрлыкка мөрәҗәгатьне һәм башка документларны (документларның күчермәләрен) электрон форматта № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куймыйча тапшыру. | Ст.39.17 ЗК РФ;<br>Федеральный закон № 63 –ФЗ;<br>Федеральный закон № 210 -ФЗ |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Законнарда дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр: Регламентка 3 нче кушымта нигезендә | ст.39.16 ЗК РФ; |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торган түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Каралмаган | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br><br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | РФ Президенты Указы № 601, п. 1 |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать һәм документлар кергән көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу | |

| | | |
|---|---|---|
| китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыксыз барып җитә алырлык чаралар һәм җайланмалар белән тәэмин итү;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда һәм «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләрне инвалидлар каршылыксыз керә алырлык итү;<br>инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка | |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләрне кулланып | затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу.<br><br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>әлеге Регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы.<br><br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә ике тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел;<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | РФ ҖК 39.14 ст.;<br>Боерык № 7;<br>№ 63–ФЗ Федераль закон;<br>№ 210-ФЗ Федераль закон |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга торглар үткәрмичә арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карары, яисә Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе проекты яки сату-алу турында шартнамә проекты, яисә җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 5 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча,

гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Министрлыкка бирә

Мөрәҗәгать һәм документларның нотариус яки документ оригиналын биргән орган (оешма, учреждение) раслаган күчермәсе почта аша юллана ала.

Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.

3.3.2. Бүлек белгече:

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итә;

Бүлеккә тапшырылган мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документларны алганда вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесне раслаучы документны карый, аның гариза бирүче исеменнән эш йөртү вәкаләтләрен тикшерә;

тапшырылган мөрәҗәгатьне һәм документларны (документларның күчермәләрен) тикшерә.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен бирсә, Бүлек белгече аларны төп нөсхәсе белән чагыштыра һәм күчермәләрне үз имзасы белән раслый.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә мөрәҗәгатьне һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм мөрәҗәгатьне теркәүдән баш тарту нигезләре булуын җиткерә, мөрәҗәгатьне һәм (яисә) документларны (документларның күчермәләрен), кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләр күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Мөрәҗәгать РФ ҖКның 39.17 статьясындагы 1 пункты нигезләмәләренә

туры килмәсә, башка вәкаләтле органга тапшырылган булса яисә мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлмәсә, Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгатьне ун көн эчендә гариза бирүчегә кайтара.

Мөрәҗәгатьне һәм аңа беркетелгән документларны кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту өчен нигез булмаса, Бүлек белгече бирелгән документларны тикшереп чыкканнан соң түбәндәгеләрне башкара:

Гариза бирүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә документларны кабул итү яки аларны кабул итүдән баш тарту турында язып куя (язуның тәртип номеры, кабул итү датасы һәм минуткача төгәллек белән вакыты, документларның гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгате максаты, үз фамилиясе һәм инициаллары);

мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлеген тутыру (җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгатькә 2 нче кушымта, документларны кабул иткән һәм исәпкә алу кенәгәсен тутырган белгечнең фамилиясе һәм инициаллары, имзасы);

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгать үтү битен тутыра (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлегенең беренче нөсхәсен бирә;

мөрәҗәгатьне, кергән документлар, мөрәҗәгать үтү бите һәм мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлегенең икенче нөсхәсе белән бергә, теркәү өчен, Министрлыкның контроль һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – Эш башкару бүлеге) юллый.

Процедура нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм Эш башкару бүлегенә юлланган мөрәҗәгать һәм документлар яки документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.3. Эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә тапшырылган, шулай ук, почта аша килгән мөрәҗәгатьне һәм аңа беркетелгән документларны рәсмиләштерә, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктларында билгеләнгән процедуралар граиза бирүче тарафыннан мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар бирелгән көнне карала.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече Эш башкару бүлегеннән мөрәҗәгатьне һәм документларны алгач Министрлыкта мөрәҗәгать үтү битен тутыра (2нче кушымта) һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар юллый:

гариза бирүче булган юридик зат турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) белешмә бирү турында Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ТР ФСХИ);

гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРИП) өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән).

җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) белешмә алу өчен - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең идарәсеннән.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белешмә (документлар) бирү турында запрослар.

3.4.2. Ведомостволара арадашлык органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән запрослар нигезендә билгеләнгән срокта соралган документларны (белешмәләрне) бирәләр.

Процедура нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булган документлар, белешмәләр яисә Министрлыкка юлланган баш тарту турында белдерү.

3.5. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга торглар үткәрмичә арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карары, яисә Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе проекты яки сату-алу турында шартнамә проекты, яисә җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр (документлар) килгәч, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга торглар үткәрмичә арендага яки милеккә бирү турында Министрлык карарын (алга таба – арендага яки милеккә бирү турында карар проекты), 7 нче һәм 8 нче кушымталарда күрсәтелгән очракларда - Татарстан Республикасы

милкендәге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе проекты яки сату-алу шартнамәсе проекты (алга таба – аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты), яисә баш тарту нигезләре һәм кимчелекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелгән җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирүдән баш тарту турында карар проекты (алга таба – баш тарту турында карар) (4 нче кушымта), аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты белән бергә юллана торган хат (алга таба - бергә юллана торган хат) әзерләү;

арендага яки милеккә бирү турында карар проектын һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын, бергә юллана торган хатны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедура юлланган запросларга җавап алынганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.2 Бүлек башлыгы арендага яки милеккә бирү турында карар проектын һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын, бергә юллана торган хатны, яисә баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм проектларны килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган аренда яки сату-алу турында карар проекты һәм шартнамә проекты, бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы арендага яки милеккә бирү турында карар проектын һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын, бергә юллана торган хатны, яисә баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар алданы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага яки милеккә бирү карар проекты һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проектын һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза үткәрү өчен Хокук идарәсенә юллый

Әлеге пункт билгели торган процедура, аннан алдагы процедура беткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән, Хокук идарәсенә юлланган арендага яки милеккә бирү турынла карар проекты һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече арендага яки милеккә бирү турында карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектына, яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза үткәрә һәм килештерелгән проектларны яисә күрсәтелгән проектлар буенча хокук идарәсе бәяләмәсен (кимчелекләр булганда) хокук идарәсе башлыгына килештерү өчен юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: арендага яки милеккә бирү турында карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектына, яисә баш тарту турында карар проектына хокук идарәсе бәяләмәсе, яки килештерелгән аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы арендага яки милеккә бирү турында карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектына, яисә баш тарту турында карар проектына хокук идарәсе бәяләмәсен, яки арендага яки милеккә бирү карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын, яисә баш тарту турында карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: арендага яки милеккә бирү турында карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектына, яисә баш тарту турында карар проектына хокук идарәсе бәяләмәсе, яки килештерелгән аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.7. Бүлек белгече арендага яки милеккә бирү турында карар проектына һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектына, яисә баш тарту турында карар проектына хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне төзәтә дә, арендага яки милеккә бирү карар проектын һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын, яисә баш тарту турында карар проектын хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтү фактын тикшерә дә, тиешле проектны килештерә.

Әлеге Регламентның 3.5.7 һәм 3.5.8 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар алданы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы килештергән һәм Бүлек белгеченә юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.9. Бүлек белгече министрның беренче урынбасарына хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән арендага бирү турында Министрлык карары проектын яки баш тарту турында карар проектын, аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын, бергә юллана торган хатны – имза куярга, милеккә бирү турында карар проектын килештерү өчен юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты һәм аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты белән бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар проекты.

3.5.10. Министрның беренче урынбасары арендага бирү турында карарга, аренда шартнамәсе проектына, бергә юллана торган хатка яисә баш тарту турында карарга кул куя һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый, яки милеккә бирү турында карар проектын килештереп, кул кую өчен министрга юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары тарафыннан кул куелган һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юлланган арендага бирү турында яки баш тарту турында карар, аренда шартнамәсе проекты, бергә юллана торган хат, яисә килештерелеп, кул кую өчен министрга юлланган милеккә бирү турында карар проекты.

3.5.11. Министр милеккә бирү турында карарны имзалый һәм министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган һәм министрның беренче урынбасарына юлланган милеккә бирү турында карар.

3.5.12. Министр урынбасары тарафыннан сату-алу шартнамәсе проекты, бергә юллага торган хат имзалана һәм милеккә бирү турында карар белән белән бергә теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллана.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары тарафыннан имзаланган сату-алу шартнамәсенең, бергә юллана торган хатның, милеккә бирү турында карар белән бергә, теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллануы.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру

3.6.1. Эш башкару бүлеге белгече арендага яки милеккә бирү турында карарны яисә баш тарту турында карар проектын, бергә юллана торган хатны терки, гариза бирүчегә шалтыратып, аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карарны бирү вакыты турында хәбәр итә яки сату-алу шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карарны гариза бирүче күрсәткән почта адресы буенча юллый. Арендага яки милеккә бирү карары эш башкару бүлеге белгече тарафыннан Бүлеккә җибәрелә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә теркәлгән һәм бүлеккә юлланган арендага яки милеккә бирү шартнамәсен, бергә юллана торган хат, яисә баш тарту турында карар.

3.6.2. Вәкил аренда яки сату-алу шартнамәсен алырга килгәндә документлар бирү өчен җаваплы эш башкару бүлеге белгече:

вәкилнең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә; юридик зат исеменнән йөри алу вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

вәкилгә арендага яки милеккә бирү шартнамәсен, яисә баш тарту турында карарны бирә һәм исәпкә алу кенәгәсенә проектларны бирү турында язып куя;

бергә юллана торган хатны бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура вәкил килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: вәкилгә тапшырылган арендага яки милеккә бирү шартнамәсе, яисә баш тарту турында карар, бергә юллана торган хат.

3.7. Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү:

Гариза бирүченең җир кишәрлеген аренда (сату-алу) шартнамәсендә киткән техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.8.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать (6 нчы кушымта);

җир кишәрлеген арендага бирү яки сату-алу турында шартнамәнең төп нөсхәсе;

Техник хата булуын таныклаган документлар.

3.8.2. Килешүдә, Белдерүдә яисә Тәкъдимдә техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче яки аның законлы вәкиле Министрлыкка шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.8.3. Эш башкару бүлеге белгече беркетелгән документлары белән бергә гаризаны кабул итеп ала да, Бүлеккә бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза һәм документлар китерелгән (кергән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гаризаның, беркетелгән документлары белән бергә, Бүлек белгеченә карау өчен юллануы.

3.8.4. Бүлек белгече документларны карый да, җир кишәрлеген аренда яки сату-алу шартнамәсенә үзгәрешләр кертү (техник хаталарны төзәтү) максатыннан арендага яки милеккә бирү турында карарга һәм аренда яки сату-алу шартнамәсенә үзгәрешләр кертү проектын әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.2 – 3.5.10, 3.6.1, 3.6.2 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яки теләсә кайсы катнашы булган затның хата турындагы мөрәҗәгатеннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: арендага яки милеккә бирү турында карарга үзгәрешләрне әзерләү, җир кишәрлеген аренда яки сату-алу шартнамәсенә үзгәрешләр проектын гариза бирүчегә юллау.

3.9. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, аренда яки сату-алу шартнамәсенә үзгәрешләр (техник хаталары төзәтелеп) белән бергә аренда яки сату-алу шартнамәсенең Министрлыкта калган нөсхәсе янына беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законды мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

Министрның карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Министр урынбасарының кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять министр исеменә бирелә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада була ала.

5.3. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт

күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
_________________

(Кемнән) _______________________________
(физик затлар өчен – фамилия, исеме, этисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәгән урыны, шәхесен раслаучы документ реквизитлары, ИНН

_______________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы,урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда теркәлүе турында мәгълүмат, ОГРН, ИНН)
_______________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Торглар уздырмыйча җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгать

Сездән _____________________________________________ нигезендә,
(РФ ҖК 39.3 ст. 2 п., 39.5 ст., 39.6 ст. 2 п., 39.6 ст.яки 39.10 ст. 2 п. каралган нигезләр күрсәтелә).
_______________________________________________________максатларында
(җир кишәрлеген файдалану максаты күрсәтелә)

___________________________________________________________________
(гариза бирүче җир кишәрлеген алырга теләгән хокук төре)

_______ кв.м. мәйданлы, кадастр номеры ________:___, ___________________

файдалануга рөхсәте булган, _______________ категорияле,
_____________________________________________ адресы буенча урнашкан
(җир кишәрлегенең урнашу урыны күрсәтелә)

җир кишәрлеген торгларсыз милек итеп бирүегезне сорыйм.

---

Өстәмә белешмә (аста күрсәтелгән шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________________________
дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынган җир кишәрлегенә алмашка бирелә торган җир кишәрлеге булса, җир кишәрлегенең дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗ өчен алынуы турында карар реквизитлары;

______________________________________________________________________________
соралган җир кишәрлегенең ясалган булса яисә аның чикләре карар нигезендә аныкланса, җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары

"Персональ мәгълүматлар турында" 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Искәрмә: Персональ мәгълүматларны эшкәртү турында әлеге гариза физик зат тарафыннан бирелә.

Гариза бирүченең имзасы (_______№________________________ышанычнамә буенча вәкил
_____________________________________/_____________________/
(вәкилнең фамилия, имя, этисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"_________ 20__ г.
______/_________________/гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштырудан катнашырга рөхсәтемне бирәм ______________________.

_______________ ___________________ ( __________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ.(соңгысы - булганда)

М.П.(юридик затлар өчен, мөһер булган очракта)

______________________________________________________________________

Искәрмә.

Җир бирү турында мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар беркетелә:

1) гариза бирүченең җир кишәрлеген торглар үткәрелмичә алу хокукын раслаган документлар;

2) «Гариза бирүченең торглар уздырмыйча җир кишәрлеге алу хокукын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 12.01. 2015, № 1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән исемлектә күрсәтелгән документлар, ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелергә тиешле документлар искәрмә булып тора, алар 9 нчы һәм 10 нчы кушымталарды күрсәтелгән (тапшыру максатына бәйле);

3) вәкил мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

4) гариза бирүче чит дәүләтнең юридик заты булса, әлеге юридик затның шул дәүләт законнарына туры китерелеп дәүләт теркәве узуы турында документларының рус теленә расланган тәрҗемәсе;

Әлеге документлар вәкаләтле органга җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать белән бергә юлланган һәм аны карау нәтиҗәләре буенча җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча карар кабул ителгән очракта, өстә күрсәтелгән документларны бирү таләп ителми.

**Җир кишәрлеге бирү турында**
**мөрәҗәгатькә**
**1 нче кушымта**

Җир кишәрлеге бирү турында
мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар
исемлеге

| Документ атамасы | Бит саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

_________________________________ _________________________________
(фамилия, инициалы) (подпись)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

_________________________________ _________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Бөтен документлар 1 данәдә тапшырыла.

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
җир кишәрлеге бирү турында
мөрәҗәгать үтү
бите

Гариза бирүче ___________________________________________________
Регистрация (керү) номеры _________________________

| № п/п | Министрлык бүлекчәләре | Кабул итеп алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| 2. | Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 5. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 8. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Министрның беренче уранбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны килештерү һәм имзалау) | | | | |
| 10. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 11. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта**

## Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр

1) җир турында законнар нигезендә торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеген алу хокукына ия булмаган зат җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать иткән;

2) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән), түләүсез файдалану, гомерлек мирас буларак яки аренда хокукында бирелгән, бары тик җир кишәрлеге бирү турында белән әлеге хокук иясе мөрәҗәгать итсә, яисә җир кишәрлеге бирү турында мөрәҗәгать РФ ҖК 39.10 статьясының 2 пункты 10 подпункты нигезендә бирелгән очраклар гына искәрмә булып тора;

3) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге гражданнар төзегән коммерциячел булмаган оешмага яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки хосусый торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы файдалану өчен бирелгән булса, әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзасының мөрәҗәгате яки җир кишәрлеге уртак файдалану милке булганда, әлеге коммерциячел булмаган оешманың мөрәҗәгате очраклары искәрмә булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә бина, корылма, гражданнарның яки юридик затларның тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан булса, корылманың (шул исәптән, төзелеш тәмамланмаган корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан булуы яисә җир кишәрлегендә РФ ҖК 39.36 статьясының 3 пунктында каралган объект урнашкан булып, ул җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә файдаланырга комачауламый яисә җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән әлеге бинаның, корылманың, аның эчендәге бүлмәләрнең, әлеге төзелеп бетмәгән объектның милек иясе мөрәҗәгать итүе искәрмә булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт һәм муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан булса, корылманың (шул исәптән, төзелеш тәмамланмаган корылма) җир кишәрлегендә сервитут шартларында урнашкан булуы яисә җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән әлеге бинага, корылмага, аның эчендәге бүлмәләргә, әлеге төзелеп бетмәгән объектка хокук иясе мөрәҗәгать итүе искәрмә булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яисә әйләнеше чикләнгән булса һәм аны бирү җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хокукта каралмаган булса;

7) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка куелган булса, ә гариза бирүче җир кишәрлеген милеккә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану өчен яки җир кишәрлеген арендага, җир кишәрлегенең резервы турындагы карарның гамәлдәге вакытыннан озынрак срокка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә, җир кишәрлеген резервка кую максатларында бирү очрагы искәрмә булып тора;

8) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса, җир кишәрлеге бирү турында шушы җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмә, төзелеп бетмәгән объект милекчесенең яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган затның мөрәҗәгате искәрмә булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булса, яки җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган булса, әлеге җир кишәрлегенең федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булып, шул җир кишәрлеген бирү турында күрсәтелгән объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате искәрмә булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган, һәм территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса, җир кишәрлеген арендага бирү

турында территорияне комплекслы үзләштерү буенча шартнамә төзелгән яки әлеге объектларны төзү бурычы куелып, территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән затның мөрәҗәгате искәрмә булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турныда хәбәр РФ ҖК 39.11 статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә РФ ҖК 39.11 статьясының 4 пункты 6 подпунктында каралган аны сату буенча аукцион үткәрелү, яки әлеге җир кишәрлеге РФ ҖК 39.11 статьясының 4 пункты 4 подпункты нигезендә ясалган булып, вәкаләтле орган тарафыннан РФ ҖК 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән очракта, аренда шартнамәсенә хокукка аукцион үткәрелү турында гариза кергән булса;

13) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки крестьян (фермер) хуҗалыгы буенча эшчәнлек итү өчен бирү турында РФ ҖК 39.11 статьясының 1 пункты 1 подпункты нигезендә хәбәр бастырылган һәм урнаштырылган булса;

14) җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә куллану җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән куллану максатларына туры килмәсә, территорияне планировкалауның расланган проекты нигезендә линияле обект урнаштыру очраклары искәрмә булып тора;

15) җир кишәрлеген бирү турында РФ ҖК 39.11 статьясының 2 пункты 10 подпункты нигезендә мөрәҗәгать ителгән очракта, соралган җир кишәрлеге, оборона һәм иминлек ихтыяҗында куллану өчен бирелгән һәм вакытлыча күрсәтелгән максатларында файдаланылмаган җир кишәрлекләренең Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган исемлегенә кертелмәгән булса;

16) бакчачылык, яшелчәчелек эшчәнлеге алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешманың җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән зурлыктан артса;

17) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яисә) территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә, федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса;

18) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә биналар, корылмалар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса;

19) җир кишәрлеген хокукларның билгеләнгән төрендә бирү рөхсәт ителми;

20) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата файлануның рөхсәт ителгән төрләре билгеләнмәгән;

21) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге җирләрнең аерым категорияләренә кертелмәгән;

22) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәттә аны бирүне алдан килештерелү турында карар кабул ителгән һәм карарның срогы чыкмаган, әлеге җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать итсә;

23) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып алынган һәм әлеге җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатлар әлеге җир алынган максатларга туры килмәсә, тузган булып танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш булган күп фатирлы йортның әлеге җир кишәрлегендә урнашкан булуы искәрмә булып тора;

24) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" Федераль Закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

25) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне ызанлау проектында яки җир кишәрлеге барлыкка китерелгән урман кишәрлекләренең проект документациясендә җир кишәрлеге күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк зуррак булса.

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта**

Җитәкчегә

____________________________________
(юридик затның атамасы)

____________________________________
(физик затның фамилиясе, инициаллары)

Сезнең ________________________________________________ урнашкан җир
(җир кишәрлеге урнашкан урын күрсәтелә)
кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьне карап, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы соралган җир кишәрлегенең
__________________________________________________________________
(җир кишәрлеген арендага яки милеккә бирүдән баш тару нигезе күрсәтелә)
сәбәпле милеккә (арендага) бирү мөмкин түгеллеген хәбәр итә.

Министрның беренче урынбасары

________________________________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта**

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы

Гариза бирүче

Гариза бирүче (вәкил) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге белән мөрәҗәгать тапшыра

Мөрәҗәгать, документлар

Бүлек белгече

Гариза бирүченең – физик затның, юридик зат вәкиленең шәхесен ачыклый. Физик яки юридик зат вәкиленең вәкаләтләрне тикшерә. Әлеге Регламентның 2.5 п.дагы исемлектә күрсәтелгән документларның булу-булмавын карый, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 п.да күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә. Гариза бирүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә документларны кабул итү яисә кабул итүдән баш тарту турында яза. Мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар исемлеген төзи.

Документларны кабул итүдән баш тарту яки гариза бирүчегә тапшырылган исемлек

Гариза бирүче

Кабул ителгән һәм тикшерелгән документлар, мөрәҗәгатькә теркәлгән документлар исемлеге

Эш башкару бүлеге белгече

Документларны кабул итү, мөрәҗәгатьне һәм документларны теркәү 1 көн

Кабул ителгән, теркәлгән документлар

Бүлек белгече

Әлеге Регламентның 2.9. п.ында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтүгә туктатуга нигез булырдай сәбәпләрнең булу-булмавын тикшерә. Электрон формада запрос юллый

Запрослар: ТР ФСХИ; ТР Росреестр; ТР буенча «ФКП Росреестр» ФГБУ филиалы 4 көн

Арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты һәм проект белән бергә юллана торган хат яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проекты әзерли. 3 көн

Арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты һәм проект белән бергә юллана торган хат яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проекты

Бүлек мөдире

Арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын һәм проект белән бергә юллана торган хатны яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проектын карап, килештерә. 1 көн

Килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты һәм проект белән бергә юллана торган хат яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проекты

Идарә башлыгы

Арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда яки сату-алу шартнамәсе проектын һәм проект белән бергә юллана торган хатны яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проектын килештерә. 1 көн

Килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты һәм проект белән бергә юллана торган хат яисә баш тарту нигезләрен күрсәтеп баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Хокукый экспертизага юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза юллый.

Хокук идарәсе белгече

Арендага яки милеккә бирү турында карар проектына, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый.
3 көн

Бәяләмә (җитешсезлекләр булса) яисә килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

Хокук идарәсе башлыгы

Карар проекты буенча бәяләмәне имзалый яисә арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә
3 көн

Килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

Имзаланган бәяләмә

Бүлек белгече

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерә һәм арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә юллый.

Хокукый экспертизага юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

Хокук идерәсе башлыгы

Арендага яки милеккә бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерә.
2 көн

Килештерелгән арендага яки милеккә бирү турында карар проекты, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

Бүлек белгече

Җир кишәрлеген арендага бирү турында карар проектын яки баш тарту турында карар проектын министрның беренче урынбасарына - кул кую өчен, җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар проектын, аренда (сату-алу) шартнамәсе проектын килештерү өчен юллый.

Министрның беренче урынбасарына кул кую өчен юлланган арендага яки милеккә бирү турында карар, аренда (сату-алу) шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Министрның беренче урынбасары

Арендага бирү карары проекты, аренда шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекта белән юллана торган хат яисә баш тарту турында карарны имзалый һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый, милеккә бирү турында карар проектын килештерә һәм кул кую өчен министрга бирә.
1 көн

Имзаланган арендага бирү карары проекты, аренда шартнамәсе проекты, аренда шартнамәсе проекта белән юллана торган хат яисә баш тарту турында карар


Килештерелгән милеккә бирү турында карар проекты
Министр
Милеккә бирү турында карар проектын имзалый һәм министрның беренче урынбасарына юллый.
1 көн
Министрның беренче урынбасары
Сату-алу шартнамәсе проектына, сату-алу шартнамәсе проекты белән юллана торган хатка кул куя һәм милеккә бирү турында карар белән бергә эш башкару бүлегенә юллый.
1 көн
Эш башкару бүлеге белгече
Арендага яки милеккә бирү турында карарны, аренда яки сату-алу шартнамәсе проекты белән юллана торган хатны, яисә баш тарту турында карарны рәсмиләштерә һәм гариза бирүчегә юллый.
1 көн
Рәсмиләштерелгән һәм гариза бирүчегә юлланган аренда шартнамәсе яки сату-алу шартнамәсе яки баш тарту турында карар.
Арендага яки милеккә бирү турында рәсмиләштерелгән карар.

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

________________

(Кемнән) ________________________________

(физик затлар өчен – фамилия, исеме, этисенең исеме (соңгысы - булганда), яшәгән урыны, шәхесен раслаучы документ реквизитлары, ИНН

________________________________________________

(юридик затлар өчен - атамасы,урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ЕГРЮЛда теркәлүе турында мәгълүмат, ОГРН, ИНН)

________________________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Техник хатаны төзәтү турында
мөрәҗәгать

Татарстан Республикасы милке булган җир кишәрлеген физик яки юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яки милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Дөрес белешмә:_________________________________________________________

______________________________________________________________________________

«____»_________ 20______ел. №________ җир кишәрлекләренә аренда (сату-алу) шартнамәсендәге техник хатаның төзәтелүен һәм тиешле үзгәрешләр кертелүен үтенәм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүе турында (күрсәтүдән баш тарту турында) мәгълүматны

______________________________________________________________________________

(язмача, электрон почта белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында Шәхси кабинетка)

_______________________________________________алырга риза

_______________ _________________ (________________)

(дата) (имза) (фамилия, исеме, этисенең исеме (булса)

М.П.(мөһер булганда)

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта**

Җир кишәрлекләре түбәндәге очракларда торглар уздырмыйча сатыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлекләре - Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән затка, әлеге пунктның 2 һәм дүрт подпунктлары белән башкача каралмаган булса;

1.1) территорияне комплекслы үзләштерү максатларында "Торак төзелеше үсешенә булышлык турында" 24 июль, 2008 ел, № 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән аренда шартнамәсе яки түләүсез файдалану шартнамәсе буенча бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлекләре;

2) территорияне комплекслы үзләштерү өчен шәхси торак төзелеше максатларында (гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлекләре искәрмә булып тора) гражданнар оештырган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлекләре – әлеге коммерциячел булмаган оешмаларның гомуми җыелышы карарында каралган булса - әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына;

3) бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы эшчәнлеге (гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлекләре искәрмә булып тора) алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага, әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлекләре;

4) территорияне комплекслы үзләштерү өчен шәхси торак төзелеше максатларында гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән һәм әлеге коммерциячел булмаган оешманың гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлеген бүлеп ясалган җир кишәрлекләре;

5) юридик затка дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән һәм әлеге юридик затның гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлеген бүлеп ясалган җир кишәрлекләре;

6) юридик затларда даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануда булган җир кишәрлекләре – әлеге юридик затларга, РФ ҖК 39.9 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән затлар искәрмә булып тора;

7) “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында” Федераль законда билгеләнгән очракларда – җир кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыгына яки авыл хуҗалыгы оешмасына;

8) авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданинга яки юридик затка бирелгән җир кишәрлеген – әлеге гражданин яки юридик зат белән шартнамә төзелгәнгә өч ел үткәннән соң яисә әлеге гражданин яки юридик зат тарафыннан әлеге җир кишәрлегенең аренда шартнамәсендә күрсәтелгән вакыт беткәнче үк торглар уздырмыйча әлеге җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе төзү турында гариза бирелгән булса, вәкаләтле органда дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында әлеге җир белән файдаланганда Россия Федерациясе законнарын бозу очраклары ачыклануы һәм аның төзәтелмәве турында мәгълүмат булмаса, әлеге гражданинга яки юридик затка аренда шартнамәсе буенча җир кишәрлегенең хокукларын һәм бурычларын тапшыру;

9) җир кишәрлекләрен гражданнарга торак пункты чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, РФ ҖК 39.18 статьясы нигезендә гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен.

**Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга торглар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта**

Җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе түбәндәге очракларда торглар уздырылмыйча төзелә:

1) җир кишәрлеген Россия Федерациясе Президенты указы яки карары нигезендә юридик затларга биргәндә;

2) җир кишәрлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә кую өчен, әлеге объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килүе шарты белән, юридик затларга биргәндә;

3) җир кишәрлеген Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты карары нигезендә социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә кую өчен, әлеге объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе субекты законнары белән билгеләгән критерийларга туры килүе шарты белән, юридик затларга биргәндә;

4) җир кишәрлеген Россия Федерациясенең халыкара бурычларын үтәү өчен, шулай ук, юридик затларга электр, җылылык, газ һәм су тәэмин итү, су агызу, элемтә өчен билгеләнгән объектларны, нефтеүткәргечләрне, федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдәге объектлары урнаштыру өчен биргәндә;

5) дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлеген, шул исәптән территорияне комплекслы үзләштерү өчен әлеге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе төзелгән затка бирелгәндә, 6 һәм 8 подпунктлар белән башкасы каралмаган очракта;

6) җир кишәрлеге шәхси торак төзелеше максатларында комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган очракта, гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлекләренең әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына яки, әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карарында каралган булса, әлеге коммерциячел булмаган оешмага бирелүе искәрмә булып тора;

7) җир кишәрлеге бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы максатларында гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган очракта, гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлекләренең әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзаларына бирелүе искәрмә булып тора;

8) җир кишәрлеге бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы максатларында яисә шәхси торак төзелеше максатларында комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлеген бүлеп ясалган һәм гомуми файдалану милкенә кертелгән очракта, әлеге коммерциячел булмаган оешмаша бирелгәндә;

9) биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеге биналар, корылмаларның милек ияләренә һәм (яисә) әлеге күчемсез милек объектлары хуҗалык алып бару хокукы белән бирелгән затларга бирелгәндә;

10) төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан җир кишәрлекләре, РФ ҖК 39.6 статьясының 5 пунктында каралган очракларда, әлеге төзелеп бетмәгән объектларның хуҗаларына төзелешне тәмамлау өчен бер тапкыр бирелгәндә;

11) юридик затлар даими (вакыты чикләнмәгән) файдалан торган җир кишәрлеге әлеге җирдән файдалунчыларга бирелгәндә, РФ ҖК 39.6 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән юридик затлар искәрмә булып тора;

12) җир кишәрлеге, "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында" Федераль законда билгеләнгән очракларда, крестьян (фермер) хуҗалыгына яки авыл хуҗалыгы оешмасына бирелгәндә;

13) төзелеп беткән территория кысаларында ясалган җир кишәрлеге, төзелеп беткән территориянең үсеше турында шартнамә төзелгән затка бирелгәндә;

13.1) җир кишәрлеген эконом класслы торак төзелеше максатыннан территорияне үзләштерү өчен яки эконом класслы торак төзелеше максатыннан территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән юридик затка эконом класслы торак төзелеше максатыннан территорияне үзләштерү өчен яки эконом класслы торак төзелеше максатыннан территорияне комплекслы үзләштерү өчен биргәндә;

13.2) дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып, территорияне комплекслы үстерү максатларында, әлеге җир кишәрлеге түләүсез файдалану хокукында арендага бирелгән физик яки юридик заттан алынган җир кишәрлеге җирле үзидарә органы инициативасы белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә әлеге шартнамә төзелү хокукы буенча аукцион

нәтиҗәләреннән чыгып, территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзелгән затка бирелгәндә;

13.3) җир кишәрлеге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзелгән затка коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары төзү өчен бирелгәндә;

14) җир кишәрлеге федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә беренче чиратта яки чираттан тыш җир кишәрлегенә ия булу хокукы булган гражданнарга бирелгәндә;

15) җир кишәрлеге РФ ҖК 39.18 статьясы нигезендә, гражданнарга торак пункты чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы өчен һәм крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларына бирелгәндә;

16) җир кишәрлеге гражданин яки юридик затка арендага бирелеп, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына бирелгәндә;

17) җир кишәрлеге дини оешмаларга, Россия Федерациясе субъекты законнары белән билгеләнгән территориядә авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру, казак җәмгыятьләренең традицион яшәү һәм хуҗалык итү рәвешен саклау һәм үстерү өчен Россия Федерациясе казак җәмгыятьләре дәүләт реестрына кертелгән казак оешмаларына (алга таба - казак оешмалары) бирелгәндә;

18) җир кишәрлеге, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен резервта булган яисә аның әйләнеше чикләнгән булса, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торгларсыз, шул исәптән, түләүсез, алу хокукына ия булган затка бирелгәндә;

19) җир кишәрлеге гражданинга печән чабу, авыл хуҗалыгы малларын көтү, яшелчәчелек өчен яисә торак пункты чикләренең аръягында урнашкан җир кишәрлеге шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен;

20) җир кишәрлеге, файдалы казылмалар буенча эш алып бару өчен, файдалы казылмалар белән эш итүчегә бирелгәндә;

21) махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янында урнашкан җир кишәрлеге махсус икътисадый зона резидентына яки идарәче компаниягә, аларны махсус икътисадый зона турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җәлеп иткән очракта, махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янындагы территориядә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш финанс чыганаклары хисабына

күчемсез милек объектлары төзү буенча функцияләр башкару һәм әлеге һәм алдарак төзелгән күчемсез милек объектлары белән идарә итү өчен бирелгәндә;

22) махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янында урнашкан җир кишәрлеге әлеге зонаның инфраструктасы объектларын төзү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль органының башкарма хакимияте белән махсус икътисадый зона инфораструктурасы үсеше өлкәсендә арадашлык турында килешү төзелгән затка бирелгәндә. Махсус икътисадый зона инфораструктурасы үсеше өлкәсендә арадашлык турында килешүнең якынча формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль органының башкарма хакимияте тарафыннан раслана;

23) концессион килешү каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүдә каралган җир кишәрлеге, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүдә каралган җир кишәрлеге, әлеге килешүләр төзелгән затка бирелгәндә;

23.1) җир кишәрлеге коммерция өчен кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү яки социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен коммерция өчен кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү яки социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү турында шартнамә төзелгән затка бирелгәндә, Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен оештырган коммерциячел булмаган оешмага;

23.2) махсус инвестиция контрактында каралган эшчәнлекне тормышка ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге махсус инвестиция контракты төзелгән затка бирелгәндә;

24) сунарчылык төрләрен тормышка ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге сунарчылык хуҗалыгы килешүе төзелгән затка бирелгәндә;

25) җир кишәрлеге сусаклагычлар һәм (яки) гидротехник корылмалар урнаштыру өчен бирелгәндә һәм әлеге объектларның урнаштырылуы территориаль планлаштыру документларында федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдәге объект буларак каралган булса;

26) автомобиль юлларына бүленгән полоса чикләрендә һәм юл буе полосасында урнашкан җир кишәрлеге җир кишәрлеге «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенә үз эшчәнлеген башкару өчен бирелгәндә;

